ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 116 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктына «, шулай ук медицина катышуы юлы белән җенесне алыштыру, җенесне алыштыруга, шул исәптән кешедә бүтән җенестәге беренчел һәм (яисә) икенчел җенес билгеләре формалаштыруга, юнәлдерелгән дару препаратларын куллануны да кертеп, һәм шәхесне таныклый торган документларга әлеге гражданнарның җенесе турында медицина катышуыннан башка үзгәрешләр кертү рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары булган затлар һәм даими яшәү урыны күрсәтелгән дәүләтләрдә булган гражданлыгы булмаган затлар» сүзләрен өстәргә;

2) 134 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктына «, шулай ук медицина катышуы юлы белән җенесне алыштыру, җенесне алыштыруга, шул исәптән кешедә бүтән җенестәге беренчел һәм (яисә) икенчел җенес билгеләре формалаштыруга, юнәлдерелгән дару препаратларын куллануны да кертеп, һәм шәхесне таныклый торган документларга әлеге гражданнарның җенесе турында медицина катышуыннан башка үзгәрешләр кертү рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары

булган затлар һәм даими яшәү урыны күрсәтелгән дәүләтләрдә булган гражданлыгы булмаган затлар» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 28 февраль
№ 3-ТРЗ